# КАРАР

19 ноябрь 2021 ел №1

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Кукмара муниципаль районының Түбән Өскебаш авылы жирлегендә гражданнар жыены нәтижәләре турында.

"Россия Федерациясендә жирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, "Татарстан Республикасында жирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2021 елның 17 ноябрендә, 2021 елның 18 ноябрендә, 2021 елның 19 ноябрендә түбәндәге сорау буенча узган гражданнар жыеннары нәтижәләре белән гражданнар жыены беркетмәсе төзелде: «Кукмара муниципаль районының Түбән Өскебаш авылы, Түбән Өскебаш авылы жирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан, укучыдан һәм студентлардан (курсантлардан), 18 яшькә һәтле 4 һәм аннан артык балалары булган күпбалалы гаиләләрдән, ялгыз әниләрдән, 85 яшь һәм аннан өлкәнрәк гражданнардан тыш, 2022 елда үзара салым кертүгә 1000 сум күләмендә риза булырсызмы?

- Түбән Өскебаш авылы Советская урамына һәм Молодежная урамнарына вак таш җәеп капиталь ремонт ясау; проект-смета документларын төзү , технадзор;
- Түбән Өскебаш авылында юлларны кыш көне карап тоту (кардан чистарту, түгү), проект-смета документларын төзү һәм килешү буенча түләү;
- Түбән Өскебашта урнашкан артезиан скважиналарына насослар сатып алу;
- Су башняларына коймa тоту( материал сатып алу, проект-смета документларын төзү һәм килешү буенча түләү;
- янгын сүндерү машинасына запчастләр сатып алу; кую; янгын сүндерү машинасына ремонт ясау; проект-смета документларын төзү һәм килешү буенча түләү;
- Түбән Өскебаш авылының Советская урамына пожар гидранты сатып алу, урнаштыру, проект-смета документларын төзү һәм килешү буенча түләү;
- зират территориясен тәртиптә тоту, зиратта склад бинасы төзү; проект-смета документларын төзү һәм килешү буенча түләү;

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар жыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган ,жыенда катнашучылар исемлегенә, 295 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнарның саны 150.
Тавыш бирү нәтижәләре буенча гражданнар жыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен 150 гражданнар жыенында катнашучы тавыш бирде; "Юк" позициясе өчен гражданнар жыенында 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар жыены карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районынын Түбән Өскебаш авыл җирлегендә гражданнар җыенын узган дип таныргa. гражданнар җыенының нәтиҗәләре - дөрес.
2. Сорау буенча карарны таныргa: «2022 елда үзара салым кертүгә Кукмара муниципаль районының Түбән Өскебаш авылы, Түбән Өскебаш авылы җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан, укучыдан һәм студентлардан (курсантлардан), 18 яшькә һәтле 4 һәм аннан артык балалары булган күпбалалы гаиләләрдән, ялгыз әниләрдән, 85 яшь һәм аннан өлкәнрәк гражданнардан тыш, 2022 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә килешеп торасызмы:

- Түбән Өскебаш авылы Советская урамына һәм Молодежная урамнарына вак таш җәеп капиталь ремонт ясау; проект-смета документларын төзү , технадзор;

- Түбән Өскебаш авылында юлларны кыш көне карап тоту (кардан чистарту, түгү), проект-смета документларын төзү һәм килешү буенча түләү;

- Түбән Өскебашта урнашкан артезиан скважиналарына насослар сатып алу;

-Су башняларына койма тоту( материал сатып алу, проект-смета документларын төзү һәм килешү буенча түләү;

-янгын сүндерү машинасына запчастләр сатып алу; кую; янгын сүндерү машинасына ремонт ясау; проект-смета документларын төзү һәм килешү буенча түләү;

-Түбән Өскебаш авылының Советская урамына пожар гидранты сатып алу, урнаштыру, проект-смета документларын төзү һәм килешү буенча түләү;

-зират террioриясен тәртиптә тоту, зиратта склад бинасы төзү; проект-смета документларын төзү һәм килешү буенча түләү;

«РИЗА» «КАРШЫ»

-кабул ителде.

3.“Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтын урнаштыру юлы белән гражданнар җыенының нәтиҗәсен бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырырга: www.pravo.tatarstan.ru,.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Авыл җирлеге башлыгы Н.М.Мөхәммәтҗанов